# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **06.12.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Районы Илбәк авыл җирлеге составына керүче Тырыш бистәсендә 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш бистәсендә гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, 2020 елда үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Тырыш бистәсенең Октябрьнең 70 еллыгы урамында щебенка түшәмәле юлларның чокырларын ремонтлау, юлларга щебенка җәю (сатып алу, транспорт хезмәте, ташу, вак таш җәю һәм тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тырыш бистәсендәге юлларны юлларны кардан чистарту.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Илбәк авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Әсәдуллина